ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 162-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Л.А. Якунин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 162-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2026 елның 19 феврале
№ 550-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
Л.А. Якунин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2011 елның 10 октябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 6; 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 6 (I өлеш); 2016, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Вәкаләтләре чоры узгач Хисап палатасы Рәисе яңа Хисап палатасы Рәисе билгеләп куелганга кадәр үз вәкаләтләрен башкаруны дәвам итә.»;

б) 2 өлешнең беренче абзацында «кандидатуралар күрсәтү» сүзләрен «кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хисап палатасы Рәисе вазыйфасыннан вакытыннан алда азат ителгән очракта, әлеге вазыйфага кандидатуралар турында тәкъдимнәр күрсәтелгән азат итү көненнән бер ай дәвамында кертеләләр. Хисап палатасы Рәисе вазыйфасына кертелгән кандидатуралар кире кагылган очракта, әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән субъектлар ике атна эчендә яңа кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертәләр. Монда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына шул ук кандидатуралар йә башка кандидатуралар кертелергә мөмкин.»

2) 6 статьяда:

а) 2 өлештә «кандидатура» сүзен «кандидатура турында тәкъдим» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Хисап палатасы Рәисе урынбасары вазыйфасыннан вакытыннан алда азат ителгән очракта, әлеге вазыйфага кандидатура турында тәкъдим күрсәтелгән азат итү көненнән алып ике атна эчендә Хисап палатасы Рәисе тарафыннан кертелә. Тәкъдим ителгән кандидатура кире кагылган очракта, Хисап палатасы Рәисе ике атна эчендә яңа кандидатура турында тәкъдим кертә. Бу чакта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына шул ук кандидатура йә башка кандидатура кертелергә мөмкин.»;

3) 7 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Хисап палатасы аудиторлары вазыйфаларына кандидатуралар турында тәкъдим Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Хисап палатасы Рәисе тарафыннан кертелә. Тәкъдим ителгән кандидатура кире кагылган очракта, Хисап палатасы Рәисе ике атна эчендә яңа кандидатура турында тәкъдим кертә. Бу чакта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына шул ук кандидатура йә башка кандидатура кертелергә мөмкин.»;

4)10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 статья. **Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары, Хисап палатасы аудиторлары вазыйфаларын биләүче затларны вазыйфадан вакытыннан алда азат итү нигезләре**

1. Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары, Хисап палатасы аудиторлары вазыйфадан вакытыннан алда Федераль законда каралган нигезләрдә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән азат ителәләр.

2. Хисап палатасы Рәисен вазыйфасыннан азат итү турындагы тәкъдим Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан, Хисап палатасы Рәисе урынбасарын һәм Хисап палатасы аудиторларын вазыйфаларыннан вакытыннан алда азат итү турындагы тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Хисап палатасы Рәисе тарафыннан кертелә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеген камилләштерү максатларында эшләнде.

Закон проекты төгәлләштерү характерында һәм республика законында кулланыла торган төшенчәләрне «Россия Федерациясе субъектларының, федераль территорияләрнең һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Федераль законга туры китерүгә юнәлдерелгән.

Закон проектында Хисап палатасы Рәисе тарафыннан үз вәкаләтләр вакыты тәмамланганнан соң Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан яңа Рәис билгеләп куйганга кадәр бурычларны үтәү механизмын күздә тоткан яңа нигезләмә өстәү тәкъдим ителә. Бу – Рәис вазыйфасына затны билгеләү кую буенча оештыру процедурасын үткәрү чорына Хисап палатасы эшчәнлеге белән җитәкчелек итүдә дәвамчанлыкны тәэмин итү өчен гамәлгә ашырыла. Мондый алым Россия Федерациясенең кайбер субъектларында кулланыла.

Законнарга кертелә торган үзгәрешләр Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторлары вазыйфасына кандидатуралар күрсәтү тәртибен камилләштерүне дә күздә тота. Кандидатураларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар, финанс комитеты аша кертү процедурасы юкка чыгарыла. Хисап палатасы Рәисенә аудиторлар вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәрне турыдан-туры кертү вәкаләте бирелә. Шулай ук закон проектында каралганча, кандидатураларны кабат керткәндә элек кире кагылган кандидатура да, яңа кандидатура да тәкъдим ителергә мөмкин, бу карар Хисап палатасы Рәисе тарафыннан кабул ителә.

**«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.